ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 22.12.2022 КАРАР
1719

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль
районы Башкарма комитетының
«Административ хокук бозулар турында
беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи
затлар хакында» 2016 елның 21 гыйнварындагы
91 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга аерым товарлар сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 2 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар хакында» 2016 елның 21 гыйнварындагы 91 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Вәкаләтле вазыйфаи затларга Татарстан Республикасы Кодексының 2.1 (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешмаларның исемнәрен һәм башка белешмәләрне элмә тактада күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата), 2.4-2.8, 2.12-2.14, 2.15 статьяның 2 өлеше , 2.16, 2.17, 3.2-3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14-3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 (тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль ташуга карата) статьяларында каралган, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү хокукын, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге вазыйфаи затларына йөкләргә:

- муниципаль контроль бүлеге башлыгына;
- муниципаль контроль бүлегенең баш белгеченә;
- тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларының баш белгеченә;
- тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларының әйдәп баручы белгеченә.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3 Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 5DD9ADE894A62EB7F6C4DA0DBC7098E466BA
Владелец: Нургаянов Ленар Фаридович
Действителен с 03.12.2021 до 03.03.2023

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов